Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 22**

Биектау ав. 2016 елның 14 декабре

**Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә;, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен җирле үзидарә органнарына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

-авыл җирлекләренең генераль планнарын, авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны раслау, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

башлыгы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының «муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» 2016 елның 14 июлендәге 12 номерлы карары үз көчен югалткан дип санау хакында "

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Биектау авылы, Х.Сафиуллина урамы, 4 йорт; Околоток-Янгасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Мухаметзянов